МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

22.04.2020 № 199

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы белән расланган Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республика-сы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карар-ларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карарын көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 10 маендагы 206 номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсенең икътисадый анализ һәм проект идарәсе бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р.Киреевага йөкләргә.

**Министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 211 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 22 апрелендәге 199 номерлы боерыгы редакциясендә)

**Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «П.Коммунасы урамы», «Камал театры» тукталышына кадәр килергә:

- 1, 6, 10а, 18, 23, 30, 35, 35а, 47, 54, 56, 63, 72, 74, 74а, 91 номерлы автобуслар;
- 1, 3, 7, 10, 17 номерлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Министрлыкның икътисадый анализ һәм проект идарәсе бүлеге (алга таба – Бүлек) телефоннары: 524-91-34, 524-91-35, 524-90-24.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mert.tatarstan.ru, электрон почта адресы: mert.pr1@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт белән идарә итү системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы: (http://www.pravo.gov.ru), 2012, 7 май, бастырып чыгару номеры: 0001201205070016);

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», 1999, 11 гыйнвар, №4, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», 2010, 9 июль, №138, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 25 ноябрендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», 2004, 26 ноябрь, №239, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып,);

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», 2008, 9 август, №160, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 7 маендагы 284 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 284 номерлы карары) («Республика Татарстан», 1999, 25 июнь, №128, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы арасында инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү формасын раслау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 377 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 377 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2006, №28-29, 0764 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары (алга таба – 325 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №30, 1057 сатья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү | 1872 номерлы ТР Законының 3 статьясы;<br>377 номерлы ТР МК карары |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 325 номерлы ТР МК карары<br>377 номерлы ТР МК карарының 1 пункты;<br>377 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 9 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү (алга таба – килешү).<br>Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килешү төзүдән баш тарту турында белдерү | 1872 номерлы ТР Законының 3 статьясы<br>377 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 2, 6 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, | Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Министрлыкта теркәлгәннән соң 40 көн эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче килгән көнне бирелә. | 284 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 6, 9, 11 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Инвестиция проектына дәүләт ярдәме алу өчен гариза (Регламентка 1 нче кушымта).<br>2. Инвестиция проектының бизнес-планы.<br>3. Инвестиция проекты буенча аның тиешле максатчан программаларда бәян ителгән тармакны үстерүнең максатчан юнәлешләренә туры килү предметына тармак компетенциясендәге башкарма хакимият органы (алга таба – тармак министрлыгы) бәяләмәсе.<br>4. Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча эксперт органнары бәяләмәләре.<br>5. Соңгы ике финанс елында һәм, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының аларны кабул итү турындагы тамгасы белән, соңгы хисап датасына керемнәр һәм чыгымнар турында бухгалтерия балanslары һәм хисаплар.<br>6. Узган һәм агымдагы еллар өчен бухгалтерия хисаплылыгының аудитор бәяләмәсе.<br>7. Кире кайтарулы нигездә бирелгән барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлардан элек бирелгән акчалар буенча кичектерелгән бурычның булмавы турында белешмә (инвестиция проектын гамәлгә ашыручы предприятие җитәкчесе һәм баш хисапчы имзасы белән ирекле формада тапшырыла). | 284 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 3, 4 пунктлары;<br>377 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 8. Ел башыннан алып һәм дәүләт ярдәме алу өчен гариза бирү вакытына кадәр шәхси акча булуы турында белешмә (агымдагы елның узган кварталларында бухгалтерия баланслары мәгълүматлары белән раслана).<br>9. Элек бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр турында белешмә (инвестиция проектын гамәлгә ашыручы предприятиенең баш бухгалтеры һәм җитәкчесе имзасы белән ирекле формада тапшырыла).<br>10. Хезмәт хакы түләү буенча бурычның булмавы һәм хезмәт хакы дәрәҗәсенең Россия Федерациясе буенча уртача тармаклы күрсәткечтән ким булмавы һәм хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакы Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь куллану бюджетыннан ким булмавы турында белешмә (инвестиция проектын гамәлгә ашыручы предприятие җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзасы белән ирекле формада тапшырыла).<br>11. Төшеп кала торган салымнарның төрләре һәм суммалары буенча, шулай ук кварталлар буенча бүлеп, проектны гамәлгә ашыру еллары буенча предприятие җитәкчесе һәм баш хисапчы кул куйган исәпләмә.<br>12. Предприятие җитәкчесе кул куйган килешү (4 нче кушымта).<br>13. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен предприятие җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган, яңа төзелә торган (сатып алына торган) милек исемлеге.<br>14. Татарстан Республикасы берләштерелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | бюджетына проектны гамәлгә ашырудан өстәмә салым керемнәренең предприятие җитәкчесе һәм баш бухгалтеры кул куйган исәпләмәсе.<br>15. Предприятиегә күрсәтелә торган дәүләт ярдәменең барлык формалары турында белешмә.<br>16. Оешманың гамәлгә кую документлары.<br>17. Гарантия алучының гарантия үтәлүенә бәйле рәвештә үзенә карата регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча йөкләмәләр үтәлешен тәэмин итүне раслаучы документлар.<br>Документлар кәгазьдә – ике нөсхәдә, килешү биш нөсхәдә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта юлламасы белән.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга | |

| | | |
|---|---|---|
| | (җибәрелергә) мөмкин.<br>Әгәр мөрәҗәгать итүче законлы вәкил яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле зат буларак катнашса, мөрәҗәгать итүчегә гаризага тиешле вәкаләтләрне раслый торган документны теркәргә кирәк.<br>Шәхси мөрәҗәгатьтә шулай ук вәкилнең шәхесен таныклаучы документ та күрсәтелә | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның мәҗбүри түләүләре буенча кичектерелгән бурычларның булмавы турында белешмә;<br>предприятиене дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;<br>предприятиенең салым исәбенә кую турындагы таныклыгы.<br>Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән. | 284 номерлы ТР МК карары белән расланган Нигезләмәнең 5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту нигезләре:<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза кергән көннән алып бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәүгә алына. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, һаваны кондиционерлау системасы, Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең интеграцияләнгән дәүләт системасына тоташтырылган мәгълүмат стендлары һәм мәгълүмат киосклары (инфомат) белән тәэмин ителгән биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керәп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалана алу (шул исәптән тулы күләмендә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Министрлык бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин ителүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәргәндә бер тапкырдан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән | |

| | | |
|---|---|---|
| | торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексלы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан: http://mert.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) инвестиция проектына дәүләт ярдәме алу өчен гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге бар.<br>Электрон документ формасында дәүләт хезмәтеннән файдалану процедурасы, аны гамәлгә ашырган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша башкарыла. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) гаризада һәм аңа теркәлә торган документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

5) инвестиция проектының бизнес-планына бәяләмә әзерләү һәм раслау;

6) килешү төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын (алга таба – ТР МК күрсәтмәсе проекты) яки, килешү төзүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килешү төзүдән баш тарту турында белдерү әзерләү;

7) ТР МК күрсәтмәсе проектын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерү;

8) ТР МК күрсәтмәсе проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрү;

9) килешү төзү;

10) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

11) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документтагы техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша, шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә, дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультация бирә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә этәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша, электрон рәвештә, кәгазьдә яки почта аша кулга тапшыру турында белдерүле заказлы юллама итеп,

Министрлыкның эш башкару бүлегенә гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Документларны электрон формада җибәргәндә, килешүдән тыш, сорала торган документларның скан күчермәләре теркәлә.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- гаризаны һәм теркәлгән, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итә;

- Бүлек белгече катнашында документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавына гариза белән документларны тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гариза һәм теркәлгән документларны терки һәм карау өчен Бүлеккә җибәрә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гариза һәм документларны, Бүлек белгече әзерләгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, теркәмичә генә кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән мизгелдән бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карау өчен Бүлеккә җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең эшен рәсмиләштерә (документларны аерым папкага туплый).

Докуметлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада җибәрелгәндә, Бүлек белгече документларны ике нөсхәдә бастырып чыгара һәм документларны аерым папкага туплый, шулай ук аерым папканы электрон рәвештә дә формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең эшен рәсмиләштерү.

3.3.4. Бүлек белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыру турында электрон формада мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның мәҗбүри түләүләре буенча кичектерелгән бурычларның булмавы турында белешмә;

предприятиене дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

предприятиенең салым исәбенә кую турындагы таныклыгы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Бүлеккә гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.5. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яки Министрлыкка җибәрелгән, соралган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.3.6. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә алынган белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә тапшырылган документлар нигезендә Бүлек белгече:

ТР Министрлар Кабинетының 284 номерлы карары таләпләренә туры килү-килмәүгә инвестиция проектының бизнес-планына экспертиза үткәрә;

инвестиция проектының бизнес-планына уңай бәяләмә проектын (алга таба – бәяләмә проекты) һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында килешү төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе) әзерли яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, килешү төзүдән баш тарту турында белдерү проектын (алга таба – баш тарту турында белдерү проекты) әзерли);

уңай бәяләмә проектын һәм ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын яки баш тарту турында белдерү проектын Бүлек башлыгына җибәрә.

Килешү төзүдән баш тарту турында белдерү (алга таба – баш тарту турында белдерү) түбәндәге нигезләрнең берсе булган очракта әзерләнә:

- тапшырылган документлар бизнес-планнарга карата белдерелгән төп таләпләргә туры килмәгәндә;

- тәкъдим ителгән инвестиция проекты Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән төп бурычларга туры килмәгәндә;

- бизнес-планда каралган чараларның максатка ярашсызлыгы, Татарстан Республикасы икътисады өчен аз нәтиҗәле булуы;

- техник-икътисадый исәпләмәләр гамәлдәге методик документларга туры килмәгәндә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә өчен җибәрелгән уңай бәяләмә проекты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проекты яки баш тарту турында белдерү проекты.

3.3.7. Бүлек Башлыгы:

инвестиция проекты бизнес-планына үткәрелгән экспертизаның дөрес булу-булмавын тикшерә;

бәяләмә проектын һәм ТР МК күрсәтмәсе проектын яки баш тарту турында белдерү проектын килештерә;

бәяләмә проектын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе яки баш тарту турында белдерү проектын килештерү өчен проектын яки инвестиция һәм инновация эшчәнлеге идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгына килештерү өчен җибәрелгән бәяләмә проекты һәм ТР МК күрсәтмәсе проекты һәм баш тарту турында белдерү проекты.

3.3.8. Идарә башлыгы бәяләмә проектын, ТР МК күрсәтмәсе проектын яки баш тарту турында белдерү проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына килештерү өчен җибәрелгән проектлар.

3.3.9. Министр урынбасары әзерләнгән проектларны килештереп, кул кую өчен министрга җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.3.8-3.3.9 пунктларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга кул кую өчен җибәрелгән проектлар.

3.3.10. Министр инвестиция проектының бизнес-планына (ике нөсхәдә) бәяләмәне раслый, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын килештерә яки баш тарту турында белдерүне имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән, инвестиция проекты бизнес-планына расланган бәяләмә, ТР МК күрсәтмәсенең килештерелгән проекты яки баш тарту турында кул куелган белдерү.

3.3.11. Бүлек белгече документлар комплектын әзерли (инвестиция проекты бизнес-планына бәяләмә күчермәсе, инвестиция проектының бизнес-планы, килешү, ТР МК күрсәтмәсе проекты белән килештерү кәгазе) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерү өчен җибәрә яисә мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерү өчен җибәрелгән документлар комплекты яисә мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән баш тарту турында белдерү.

3.3.12. Материалларны карау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын килештерү ТР Министрлар Кабинетының 284 номерлы карарының 10 пунктында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

3.3.13. Бүлек белгече, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан килешенгән документлар алынганнан соң, Министрлык бәяләмәсен һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының килештерү кәгазен теркәп, килешү төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура килешенгән документлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан килгән мизгелдән бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлык бәяләмәсен һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының килештерү кәгазен теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән ТР МК күрсәтмәсе проекты.

3.3.14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсен карау һәм раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 284 номерлы карарының 12 пунктында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

3.3.15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты буенча тискәре карар чыгарылганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мөрәҗәгать итүчегә дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе проекты буенча Министрлыкка тискәре ТР МК карары алынганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

3.3.16. Бүлек белгече, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе расланганнан соң, Министрлыкның юридик бүлеге белән килешү төзи һәм кул кую өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе Министрлыкка кергәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның юридик бүлеге белән килештерелгән килешү проекты.

3.3.17. Министр килешүгә кул куя (биш нөсхәдә) һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр кул куйган килешү.

3.3.18. Бүлек белгече килешүне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә (аның ышанычлы затына) бер нөсхәсен бирә.

Килешүнең бер нөсхәсе килешү белән папкага теркәлә һәм Бүлектә саклана.

Мөрәҗәгать итүчегә (аның ышанычлы затына) килешү тапшыру процедурасы мөрәҗәгать итүче килгән көндә гамәлгә ашырыла.

Килешүнең калган нөсхәләре килешүне рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм тармак министрлыгына җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган (почта аша җибәрелгән) килешү.

3.4. Техник хаталарны төзәтү.

3.4.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче

тарафыннан кәгазьдә тапшырыла яки почта аша заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә.

3.4.2. Министрлыкның эш башкару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.4.3. Бүлек белгече документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, мөрәҗәгать итүчегә шәхсән, мөрәҗәгать итүчедән документның техник хатасы булган төп нөсхәсен алып, кул куйдыртып, министр (министр урынбасары) кул куйган, төзәтелгән документны тапшыра яки, бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшыру очрагында, документны алып булу мөмкинлеге турында мөрәҗәгать итүче адресына хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм министрның дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, Министрлыкның вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләрен үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, гаепле дип танылган Министрлыкның вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Бүлек эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Шикаять – Министрлыкка, ә Татарстан Республикасы икътисад министры карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт хезмәткәре, Татарстан Республикасы икътисад министры карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mert.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый

төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда, – теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

